КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 август г.Казань № 843

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче; 2016 ел, 15 февраль, 73 нче; 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче; 2018 ел, 22 сентябрь, 828 нче; 2019 ел, 12 апрель, 281 нче; 2019 ел, 29 июль, 629 нчы; 2020 ел, 25 август, 737 нче; 2021 ел, 19 апрель, 257 нче, 2021 ел, 8 декабрь, 1197 нче, 2022 ел, 8 июнь, 540 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага, аңа түбәндәге эчтәлекле 30 һәм 31 пунктларны өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «30. | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтү бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон рәвештә хезмәтләр күрсәтелгәндә регламент срогы бозылмыйча күрсәтелгән дәүләт хезмәтләре өлеше, процент | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100,$<br>монда:<br>А - дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтү бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон рәвештә хезмәтләр күрсәтелгәндә регламент срогы бозылмыйча күрсәтелгән дәүләт хезмәтләре саны, берәмлек;<br>В - Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында электрон рәвештә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомуми саны, берәмлек |
| 31. | Массакүләм социаль әһәмиятле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомуми санында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталыннан һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып, муниципаль хакимияте органнарына һәм дәүләт | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100,$<br>монда:<br>А – Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталыннан һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып, дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләргә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләргә шәхсән бармыйча, электрон рәвештә мондый хезмәтләр күрсәтүдән файдалану өчен мөрәҗәгатьләр өлеше, процент | | | шәхсән бармыйча, электрон рәвештә массакүләм социаль әһәмиятле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалану өчен мөрәҗәгатьләр өлеше, процент<br>В – Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталыннан һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып, дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләргә шәхсән бармыйча, электрон рәвештә массакүләм социаль әһәмиятле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалану өчен мөрәҗәгатьләр саны, берәмлек». |

2. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин